КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

# БӘЯ СЫЙФАТКА ЙОГЫНТЫ ЯСАМЫЙ

## ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе Татарстанның кулланучылар базарында «сыр» дип сатыла торган сыр продуктларын ачыклады.



Этил спирты, алкоголь продукциясе җитештерү, аларның әйләнеше һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча ТР Дәүләт инспекциясендә республика кибетләрендә сатыла торган сырларга дегустация узды. Инспекция белгечләре сәүдә челтәрләрендә килограммы 350-700 сум тәшкил иткән продукцияләр сатып алды.

– Шунысы кызганыч, 36 үрнәкнең өчесе билгеләнгән таләпләргә туры килү ягыннан тикшерүне уза алмады. Безгә кулланучылар сырның сыйфатына зарланып шактый еш мөрәҗәгать итә. Әмма бу күбесенчә базарда сатып алынган билгесез продукт булып чыга. Зур сәүдә челтәрләрендә продукцияне алыштыру фактлары булгалый – җитештерүче аны танылган марканыкы дип сата, – ди ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе Җәүдәт Әхмәтханов.

Ул шулай ук сыр тиешенчә төрелгән һәм маркировкаланган очракта, сатып алучының продукт турында бөтен мәгълүматны белүен искәртте. Әмма кибетләр товарны төрү белән үзләре шөгыльләнсә, кулланучы аның турында барлык мәгълүматны алмаска мөмкин.

Лаборатория тикшерүләре узган барлыгы 15 үрнәккә дегустация үткәрелде.

– Дегустация нәтиҗәләре күрсәткәнчә, бәя сыйфатка йогынты ясамый. Ике җитештерүче (берсе – Татарстанныкы, икенчесе – башка төбәктән) сыр ясаганда үсемлек майларын кулланса да, этикеткасында аның «сыр продукты» түгел, ә сыр икәнлеген күрсәткән. Өченче үрнәк исә микробиологик күрсәткечләре буенча тиешле таләпләргә туры килми дип табылды, – ди ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге башлыгы Розалия Арсланова.

**Табигый продуктны табигый булмаганына алыштыру җитештерү чыгымнарын киметә, әмма кулланучы ярык тагарак каршында кала. Инспекциядә барлык мәгълүматлар административ тикшерү үткәрү өчен Кулланучыларның хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәткә тапшырылачагын искәрттеләр.**

# Судта кулланучыларның хокукларын ничек якларга

## ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе моңа аңлатма бирә.

**Әгәр кулланучының законлы таләпләрен үтәүдән баш тарталар икән, ул «Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы РФ законының 17 маддәсе нигезендә судка мөрәҗәгать итә ала.**

Кулланучыларның хокукларын яклау турындагы шикаять судка дәгъва белдерүче сайлаганча, оешма урнашкан урын буенча бирелергә мөмкин. Әгәр җавап бирүче шәхси эшкуар икән, эшмәкәр яки дәгъва белдерүченең яшәү урыны буенча, шулай ук килешү төзелгән яки башкарылган җирдәге судка мөрәҗәгать итәргә була. Әгәр оешмага карата шикаять аның филиалы яки вәкиллеге эшчәнлегеннән белдерелгән очракта, ул судка алар урнашкан урын буенча бирелергә мөмкин. Кулланучылар, кулланучыларның хокукларын бозуга бәйле шикаятьләр буенча башка дәгъвачылар Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законы нигезендә, дәүләт пошлинасы түләүдән азат ителә.

Әмма судка мөрәҗәгать итәр алдыннан, судка кадәр тәртиптә үзеңнең саклану чараларын күрү хәерле. Кулланучылар хокукларын яклау турындагы закон гамәлдә булган шушы вакыт эчендә суд практикасы күрсәткәнчә, сатучылар, җитештерүчеләр һәм башкаручыларга, кулланучы үзенең законлы таләпләрен белдергән очракта, низагны судта түгел, ә тыныч юл белән хәл итү файдалырак.

Еш кына сатучылар, җитештерүчеләр һәм башкаручылар, кулланучының хокукый белеме сай икәнен күргәч, ул үзенең хокуклары өчен ахырга кадәр көрәшмәячәк дип уйлый һәм аның законлы таләпләрен иректә тәртиптә үтәүдән баш тарта. Шуңа күрә әгәр таләпләреңнең үтәлүен теләсәң, кайвакыт аларны дөрес итеп аңлатып бирү дә җитә.

Сатучы, җитештерүче яки башкаручы кулланучының законлы таләпләрен үтәүдән баш тартса, судка мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Шул ук вакытта таләпләрең гамәлдәге законнарга туры килүенә инанырга, үзеңнең хаклы икәнлегеңә дәлилләр китерергә, үз хокукларыңның бозылуын раслый торган документлар җыярга кирәк, шул исәптән таләпләрне үтәүдән баш тарту турында язылган дәгъва кәгазен дә (әгәр дә ул булса). Судка мөрәҗәгать итәр алдыннан, таләпләрең нигезле булуын раслый торган документлар әзерләү зарур. Мондый документларның исемлеге бәхәснең эчтәлегенә бәйле, ләкин һәр очракта да дәгъва гаризасы тутырылырга тиеш. Гаризада дәгъвачының җавап бирүчегә үзенең бозылган хокукларын кире кайтару турындагы таләбе күрсәтелергә тиеш. Анда дәгъваның бәясе күрсәтелә, бу - дәгъвачы тарафыннан белдерелгән милеккә таләпләрнең ничә сумга бәяләнүен аңлата. Гариза дәгъвачы яки аның вәкиле тарафыннан имзалана.




Дәгъва гаризасы бернечә нөсхәдә тутырыла, аларның исәбе җавап бирүчеләрнең санына бәйле.

Иң мөһиме – судлардан курыкмаска кирәк. Кайчагында бары тик судта гына кулланучының законлы таләпләре үтәлүенә ирешергә мөмкин.

АТНА ВАКЫЙГАЛАРЫ
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Татар–информ» мәгълүмат агентлыгында әзерләнде.

Генераль директор – Шамил Мөхәммәт улы Садыйков.
Баш редактор – Рәмис Нурмөхәммәт улы Латыйпов.
Шеф–редактор – Алсу Исмәгыйлева.
Җаваплы редактор – Лилия Гаделшина.
Дизайн–верстка – Светлана Щеглова.
Корректор – Раис Габдуллин.

Тел.: (843) 222–09–83 (1304; 1414)
Редакция һәм нәшир адресы:
420066, Казан ш., Декабристлар ур., 2нче йорт.
Эл.адрес: info@tatar–inform.tatar
Реклама хезмәте телефоны: (843) 570–31–07

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсендә Федераль күзәтчелек хезмәтенең (РОСКОМНАДЗОР) Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2014 елның 9 гыйнварында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы: ПИ №ТУ16–01140
Басмага бирү вакыты: 28 ноябрь 2018,
график буенча – 24.00, гамәлдә – 24.00

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ

Нәшир адресы:
420097, Казан ш., Академия ур., 2
**Басылу урыны:**
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
«Идел–Пресс» полиграфия–нәшрият комплексы.,
Казан ш., Декабристлар ур., 2
Тираж –46 940 экз

**Гомуми тираж: 65 568 экз.**

Редакция фикере автор фикере белән туры килмәскә мөмкин. Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Реклама игъланнарының дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
© Язмаларны күчереп бастыру фәкать редакция рөхсәте белән генә башкарылырга тиеш. Газета атна саен чыга. Бәясе ирекле.

*«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла*

16+